РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2025 с. Сарманово № 70

2025 елның 17 февралендәге 54 номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы карарын гамәлдән чыгару турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 174.3 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында" 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының салым чыгымнарын бәяләүнең салым чыгымнары исемлеген төзү тәртибен раслау турында» 2025 елның 17 февралендәге 54 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Хөснимәрдановага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Ф.А. Валиев